| ГЛАВА ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2020 с.Старое Дрожжаное № 22

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы каршындагы Икътисадый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы каршындагы Икътисадый совет турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 06.03.2014 ел № 13 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Совет рәисе советны җитәкли, аның утырышларын алып бара, Советның көн тәртибен раслый.»;

12 пунктны 12.1 пункты дип санарга;

14 пунктта «үткәрелергә мөмкин» сүзләрен «үткәрелә» сүзе белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 16.1 пункт өстәргә:

«16.1. Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Совет карарлары утырышта катнашкан Совет әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителә.».

2. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Чүпрәле муниципаль район
Башлыгы: М. Р. Гафаров